Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлегенең Түнтәр торак пунктында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 28 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегенең Түнтәр торак пунктында халык җыены Карар кабул итте:

1. 2020 елда яшәү урыны буенча теркәлгән, Урта Көшкәт авыл җирлеге Түнтәр торак пункт территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. Балтач районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Түнтәр авылында яшәүче, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәк ялгыз пенсионерлар һәм өлкәннәр өчен үзара салым суммасының 95% ы күләмендә ташлама билгеләнгән, көндезге уку формасында белем алучы студентлар өчен үзара салым суммасының 50% ы күләмендә ташлама билгеләнгән.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Перфилов Ю. М.